**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Килдураз авыл җирлегенең Бәбки авылында гражданнар җыены карары**

21 ноябрь 2025 ел № 1

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Килдураз авыл җирлегенең Бәбки авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2026 елда Килдураз авыл җирлегенең Бәбки авылында территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия балигъ булган гражданнарның һәркайсыннан 2000 сум күләмендә үзара салым җыюны кертергә.

2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (урамнарны яктырту лампалары, яктылык техникасы җайланмалары урнаштыру өчен монтаж материаллары һәм арматура комплектлары сатып алу, урамнарны яктырту лампаларын алыштыру);

3. Җыен нәтиҗәләрен Килдураз авыл җирлегенең Бәбки авылында авылында авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Килдураз авыл җирлеге башлыгы ________З.З.Әхәтов

Гражданнар җыены секретаре _________ Л.И.Шәфигуллина